Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№5 (56)

14 февраль 2013 ел

## • Универ хәлләре

**7-8 ФЕВРАЛЬ КӨННӘРЕНДӘ** Екатеринбургта Россиянең беренче Президенты Б.Н.Ельцин ис. Урал федераль университеты базасында «Вузда белем бирүнең яңа технологияләре» исеме астында **X ХАЛЫКАРА ФӘННИ-МЕТОДИК КОНФЕРЕНЦИЯ УЗДЫ**. Аның кысаларында үткәрелгән «Электрон белем бирүне гамәлдә куллану» конкурсында «КФУның дистанцион белем бирү системасы» проекты беренче урынга лаек булды. Конкурста проектны Белем бирү ресурсларын арттыру департаменты директоры урынбасары Рамил Валитов тәкъдим итте.

• • • •

**7 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ** Филология һәм сәнгать институтында **«ШИГЪРИ САБАНТУЙ» КОНКУРСЫНА ЙОМГАК ЯСАЛДЫ**. Чара бишенче мәртәбә ТР Язучылар берлеге һәм «Әллүки» иҗат берләшмәсе ярдәме белән уздырыла. Җиңүчеләр «Сабантуй Батыры», «Яшь батыр», «Еракган торып» номинацияләрендә көч сынашты. «Сабантуй Батыры» исеменә Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара бәйләнешлар институты студенты Элнар Байназаров лаек булды.

• • • •

**8 ФЕВРАЛЬ**, Россиядә Фән көнендә, Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәгендә КФУ һәм әлеге үзәк арасында фән, мәгариф һәм инновацияләр өлкәсе буенча **КИЛЕШҮГӘ** КФУ ректоры **ИЛШАТ ГАФУРОВ** һәм РФАның Казан фәнни үзәге җитәкчесе **ОЛЕГ СИНЯШИН КУЛ КУЙДЫ**. Чарада шулай ук ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, премьер-министр урынбасары Равил Моратов, Дәүләт Советы рәисе урынбасары Римма Ратникова, Казан мэры Илсур Метшин да катнашты. Әлеге килешү фән дөньясында мөһим урын алып тора.

• • • •

Шул ук көнне Тарих музеенда **«ТРНЫҢ ИҢ ЯХШЫ ЯШЬ ГАЛИМЕ-2012» КОНКУРСЫНА НӘТИҖӘ ЯСАДЫЛАР**. Өч номинация буенча үткәрелгән конкурска ике йөздән артык кеше гариза биргән һәм кырык бер кеше финалга чыккан. «Табигый фәннәр өлкәсендә иң яхшы яшь галим» номинациясендә Фундаменталь медицина һәм биология институты студенты Алсу Җамалиева җиңү яулады. Шушы ук номинациядә өченче дәрәҗәдәге диплом белән А.М.Бутлеров ис. Химия институтының аналитик химия кафедрасы өлкән укытучысы Гүзәл Зиятдинова бүләкләнде. Башка номинацияләрдә дә КФУның конкурста катнашкан яшь галимнәре дипломнарга ия булды.

• • • •

**8 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ** КФУның Чистай филиалында гуманитар һәм социаль-икътисади фәннәр кафедрасы доценты Ю.Егорова җитәкчелегендә «Социаль системалар белән идарә итүнең актуаль проблемалары» темасына **СЕМИНАР-ДИСКУССИЯ ҮТТЕ**. Анда «Дәүләт һәм муниципаль идарә итү» юнәлеше буенча укучы студентлар катнашты.

• • • •

**10 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ** КФУның Алабуга институтында аның **ЮБИЛЕЙ ЕЛЫНА СТАРТ БИРЕЛДЕ**. Ноябрь аенда ул үзенең 115 еллыгын бәйрәм итәчәк. Уку йорты Алабуга Епархиаль (Стахеев) хатын-кыз училищесы эшчәнлеген дәвам итә. Юбилей кысаларында бик күп чаралар уздыру күздә тотыла.

• • • •

**11 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ** Тарих институтында **ТЮРКОЛОГИЯ ТҮГӘРӘГЕНЕҢ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Анда студентлар Рамзи Вәлиевнең «Беренче суверенитет турында» темасына докладын тикшерделәр.

• • • •

**18 ФЕВРАЛЬДӘН БАШЛАП**, Филология һәм сәнгать институтында **ТАТАР ТЕЛЕ БУЕНЧА БУШЛАЙ КУРСЛАР ЭШЛИ БАШЛЫЙ**. Алар, февральдән башлап, майга кадәр дәвам итәчәк. Укыту ике юнәлеш буенча алып барылачак: телне өйрәнә башлаучылар һәм өйрәнүне дәвам итүчеләр өчен. Тулырак мәгълүматны Казан халыкара лингвистик үзәгендә (Татарстан ур., 2 йорт, 220 каб.) алырга мөмкин. Белешмәләр өчен телефон: 8(843)293-94-52.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*




prav.tatar.ru

# «Казан - үсеш юлында»!

**Динә МӨХТӘСИПОВА**, хәбәрче

**Кичә Казанга бер көнлек эш сәфәре белән Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Федерация Советы рәисе Валентина Матвиенко килде.**

Федерация Советы рәисе, ТР президенты Рөстәм Миңнеханов, КФУ ректоры Илшат Гафуров һәм башка рәсми шәхесләр катнашында «РФ субъектларында коррупциягә каршы торуның хокукый һәм институциональ нигезләрен камилләштерү» дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференция узды. Чарада Россиянең 33 төбәгеннән һәм Казахстаннан хокук буенча белгечләр, хакимият органы вәкилләре катнашты. Әлеге темага багышлап, ил төбәкләре мәйданында узачак конференцияләр циклы Татарстанда башланып китүнең җитди сәбәбе бар. Татарстан – коррупциягә каршы торуның республика, ведомстволар һәм муниципалитетлар дәрәҗәсендәге механизмнарын беренчеләрдән булып эшләгән төбәк. Конференциядә катнашучылар антикоррупция сәясәтен реальләштерү юлларын эзләделәр, тәҗрибә уртаклаштылар.

Бу Валентина Матвиенконың Казанга, Федерация Советы спикеры булырак, беренче тапкыр килүе. Федерация Советы рәисе Валентина Матвиенко Казандагы үзгәрешләргә таң калуын әйтте. «Казан шундый зур тизлек белән алга бара. Шул ук вакытта борынгы Казан рухы да саклана, ул яшь, матур һәм үсештә», – диде, фикерләре белән уртаклашып.

Эш сәфәре вакытында, Федерация Советы рәисе «IT-парк» югары технологияләр өлкәсендәге технопаркта, Татарстан Халыклар дуслыгы йортында, Универсиада авылында булды.

Ул эш сәфәре вакытында «IT-парк» югары технологияләр өлкәсендәге технопаркта Казан югары уку йорты студентлары белән очрашты. «Универсиада вакытында сез толерантлык буенча имтихан бирәчәксез. Казан студентлары үз дәрәҗәсен төшермәс дип уйлыйм», – диде. Мәскәү кунагы шулай ук югары уку йортын тәмамлагач, билгеләп эшкә җибәрүгә каршы булуын әйтте. «Әгәр студентлар үзләре теләк белдерсә, без шат кына булачакбыз», – дип фикерләре белән уртаклашты. Федерация Советы рәисе Универсиада авылында да булды һәм аның халәтен югары бәяләде.

*Мәгълүмат «Tatar-inform» сайтыннан алынды*

## • Чара

# Яшь күңелле галим

**Дания ФАТЫЙХОВА,** хәбәрче

**13 февраль көнне Физика институты үзендә бик күп кунаклар кабул итте. Чара совет физигы, СССР Фәннәр академиясе әгъза-корреспонденты Семен Александр улы Альтшулерның (1911-1983) истәлегенә багышланган юбилей семинары кысасында үткәрелде. Семен Альтшулер фәндә нейтронның магнитлы моментын һәм акустик парамагнит резонансын алдан әйтүе белән танылу алган.**


Диана Поварова фотосы

Галим бик күп атаклы кешеләре белән дан тоткан Витебск шәһәрендә туган. Белем алу өчен югары уку йорты итеп, ул Казан университетын сайлый. 1928 елда физика-математика факультетына укырга керә. 1932 елда аны тәмамлап, аспирантурада гыйлем туплавын дәвам итә. 1936 елга инде диссертациясен яклауга ирешә. Шулай итеп, галим тормышын Казан белән бәйли.

**Ахыры 2нче биттә.**

Чара

# Яшь күңелле галим

Башы 1нче биттә.



Озак еллар буе Казан университетында гамәли физика курсларын алып бара, җирле галимнәр белән хезмәттәшлек итә. Сугыш башлангач, үз теләге белән фронтка китә. Аннан исән-имин әйләнеп кайткач, фәнни эшчәнлеген дәвам итә.

Семен Альтшулер – Казан университетында электрон магнитлы резонанс өлкәсендәге эксперименталь тикшеренүләрне яңартып җибәргән кеше. Шул эксперимент интерпретациясендә катнашу өчен, ул бүтән фән өлкәсендәге аспирантларны да җәлеп итә алган. 1969 елда Альтшулер электрон магнитлы резонансны ачуга 25 ел булу уңаеннан фәнни конференция оештыра. Шул вакытта Казанга беренче тапкыр АКШ, Франция, Голландия, Швейцария, ГДРдан күп кенә галимнәр килә.

Семинар барышында профессор Борис Иван улы Кочелаев галимнең тормыш юлы һәм эшчәнлеге белән таныштырды. «Ул чын мәгънәсендә югары авторитетлы кеше иде. Үзенең оптимизмы һәм яшь күңелле булуы белән бөтен кешене җәлеп итә ала иде. Аны чит илләрдә дә яхшы беләләр һәм яраталар иде. Бу турыда күпсанлы рәхмәт хатлары да әйтеп тора», – диде ул.

Аннан соң сүз профессор Владимир Александр улы Голенищев-Кутузовка бирелде. Галим шулай ук Семен Альтшулерга бәйле хатирәләре белән уртаклашты һәм үзенең эшчәнлеге белән таныштырды. Ул парамагнитлы релаксация юнәлешендә эшли икән. «Әгәр баштан ук болай авыр икәнен белгән булсам, бу эшкә алынмаган булыр идем», – дип көлеп куйды Владимир Голенищев-Кутузов.

Доцент Александр Василий улы Дуглав үзенең эшчәнлеге белән таныштыру барышында акустик бәйләмгә катнашы булган эксперименталь проблемаларны атап узды һәм интерактив тактада ике эксперимент схемасын тәкъдим итте. Аның чыгышыннан соң, Александр Леонид улы Ларионовка сүз бирелде. Ул, үз чыгышында, акустик парамагнит резонансын ачу һәм тикшерү тарихы белән таныштырды.

Җуелмас байлык

# Фән сарае

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гамәли коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты







Университетның киң танылу алган архитектура ансамблен торгызу эше Петр Гаврилович Пятницкий исеме белән бәйле. Ул гимназия һәм Тенишев йортларын үзгәртеп коруны үз өстенә ала. Архитектор бер линиядә аерым торган бу ике бинаны бер корпуска берләштерүгә ирешә.

Аның юлында күп кенә авырлыклар килеп чыга: Тенишев йорты (хәзер – төп бинаның көнбатыш ягы) гимназия йортына (хәзер – төп бинаның көнчыгыш ягы һәм үзәк порты) караганда таррак, өстәвенә аның колонналары һәм гөмбәзе дә булмаган. Әлеге ике бина арасындагы 34 метр аралыкны нишләтергә, дигән сорау да көн үзәгендә була. Тик архитектор бу сорауларның барысына да җавап таба. Әлеге ике йорт арасына салынган яңа диварлар ярдәмендә ул аларны берләштерә. Биналарның төрле киңлеге мәсьәләсен Пятницкий ишегалды ягыннан куәтле тартма төзеп кую ярдәмендә чишә. Нәтиҗәдә әлеге тартма югары этажга алып менә торган киң парад баскычларын һәм залларга керү мәйданчагын үзенә сыйдыра. Бу корылма икеләтә функция үти: ул йортлар арасындагы киңлек аермасын юкка чыгара һәм бинаның диварын ныгыткан үзенчәлекле контрфорс хезмәтен башкара.

Тышкы план эчке төзелеш мантыйгын да билгели. Тәбәнәк корылманың бер кварталга диярлек сузылган бертөрлелегеннән котылу өчен , Пятницкий хәзерге Кремлевская урамына чыгып торган фасадны 12 үзәк һәм алтышар ян колонна белән бизи. Колонналар һәм аларны кабатлаучы пилястрлар сәнгатьле вертикаль сызыклар барлыкка китерә. Алар бинаны тагын да биегрәк һәм мәгърур итеп күрсәтә, аңа сынлылык, төзлек өсти. Пятницкий күз белән күреп кабул итүгә зур игътибар биргән. Бүген беребез дә университет колонналарының мичкәсыман формада булуын сизмибез. Каршылык менә нәрсәдә: әгәр алар төз булса, тамашачыга конус формасында күренер иде. Башта ук караш үзәк коллонага төшә. Әлеге үзәк өлешнең өстенә шактый эре аттик куелган. Боларның һәммәсе бинаны мәһабәт итә һәм гыйбадәтханә характеры өсти. Пятницкий моны уйлап, чыннан да фән сарае төзүен күз алдында тотып эшләгән.

Фасадның декоры җитди һәм тыйнак. Кәрнизнең горизонталь сызыгы бинаның бөтен периметры буйлап чиратлашучы модульоннарга таяна. Бу җитди гадилек, әйтерсең лә, биредә хакимият түгел, ә әхлакый югарылык өстенлек итүе хакында сөйли. Төп бинага керә торган урынны рыцарь башлыгына утыртылган ябалаклар бизи. Бу сынлы сәнгать әсәренең мәгънәсе символик: университет хакыйкать өчен каһарманнарча көрәшүче акыллы галимнәрнең фән һәм сәнгать йорты булып тора. Төп бинаның эчке күренеше бүген дә үзенең гадилеген һәм бөеклеген саклый.

Бәйге

# Идел буе студентлары, берләшегез!

## яки «Милли хәзинә» яңа сулыш алачак

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты

Һәр халыкның меңнәрчә елларга сузылган тормышында тупланган тәҗрибәсе, гореф-гадәтләре, бай тарихы, тәрбия зиннәтләре бар. Хәтердән башка йола, тәрбиядән башка рухи хәзинә, рухи хәзинәдән башка халык – тарихсыз. Шуны истә тотып, КФУда инде менә дүртенче мәртәбә халыклар иҗаты Идел буе яшьләр фестивале уздырыла. Башка елларда ул «Милли хәзинә» дип аталган булса, быел ул I Идел буе халык иҗаты студентлар фестивале «Национальное достояние» дигән яңа атама һәм дәрәҗә алды.

Исеменнән күренгәнчә, ул төрле милләт һәм дин вәкилләреннән торган яшьләрдә үзара мәдәни толерантлык һәм хөрмәт тәрбияләүгә юнәлтелгән. Әлгеге фестиваль студентларда туган илгә, халыкларның үзенчәлекле һәм кабатланмас мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләүдә дә зур эш башкара.

Гадәттә, чарада Идел буе халыкларының булачак ана теле укытучылары гына катнашкан булса, быелгы фестивальдә Идел буендагы классик университетларның теләсә кайсы факультетында белем алучы һәр студент (башка еллардагыдан аермалы буларак, сәнгать факультеты студентлары да) үз көчен сынап карый алачак. Элек фестиваль күбрәк үзешчәнлеккә корылган булса, быел һөнәрилеккә өстенлек бирелә. Шул рәвешле чараның географик җирлеге дә, сәнгатьчә оештырылу масштабы да зурдан. Инде Башкортстан, Мордовия, Удмуртия, Чувашстан, Саратов, Киров югары уку йортларында



укучылар катнашырга теләк белдергән. Шулар арасыннан Саратов Дәүләт университеты аеруча активлык күрсәткән: аеруча сәләтле 45 студент фестивальдә үзенчәлекле чыгышлары белән тамашачыны һәм жюри әгъзаларын таң калдырырга җыена.

Фестивальне оештыручыларның берсе, КФУның Филология һәм сәнгать институтының музыка сәнгате кафедрасы доценты Эльвира Закирова әйтүенчә, быел яңа номинацияләр дә өстәлгән.Катнашучыларның «Вокал», «Бию», «Инструменталь жанр», «Сәнгатьле сүз», «Вокаль-хореографик ансамбль», «Вокаль-инструменталь ансамбль», «Декоратив сәнгать» номинацияләреннән тыш, өряңа «Театр» һәм «Дизайн» юнәлешләрендәдә көчләрен сынап карау мөмкинлеге бар. Төп таләп: чыгышларда Идел буе халыкларының бай гореф-гадәтләре, рухи кыйммәтләре чагылыш табарга тиеш.

Әлеге чарага үзебезнекеләр дә тырышып әзерләнә. 14 февраль көнне КФУара сайлап алу туры узачак. Төрле факультетларда укучы студентларның иң лаеклылары гына фестивальдә университетыбыз данын яклаячак. «Ал Зәйнәбем » вокал триосы да җыр юнәлешендә үзен сынап карамакчы.


Бүген университетыбызда фестивальне оештыру буенча кызу эш вакыты. Кунакларны каршы алу һәм озатып йөрү өчен, студентлардан торган волонтерлар төркеме әзерләнә. Фестивальгә башка төбәкләрдән килүче студентлар өчен дә шәп яңалык: быел алар Универсиада авылында бушка яши алачак. Кунаклар өчен төрле күңел ачу чаралары, экскурсияләр программасы каралган.

Фестивальне ачу тантанасы 19 февральгә билгеләнгән. Шул ук көнне килгән кунакларга КФУның «Мизгел» халык театры үз спектаклен күрсәтәчәк. 20се көнне төрле мәйданчыкларда сайлап алу турлары узачак. Чыгышларның иң үзенчәлекләре, әзерләнгән номерларның иң «каймагы» гына Гала-концертта катнашу хокукы алачак. Гала-концерт исә 21 февральдә Уникс концертлар залында үтәр, дип көтелә.

• Юксыну

**Кеше китә, җыры кала, дигән гыйбарәне һәркемгә карата әйтеп булмый. Кемнәрдер бакый дөньяга күчсә дә, аның рухы, ул кылган гамәлләр, аның белән бәйле истәлекләр мәңге күңелгә уелып кала. Бер ел элек арабыздан киткән татар халкының бөек улы Фәнис Яруллинның шушы көннәрдә 75 яшьлек Юбилее. Фәнис абыйга ничә яшь тулса да, вафатына күпме гомер узса да, ул безнең йөрәк түрләрендә изге күңелле, яшь, чибәр, җор телле, һәрвакыт күтәренке кәефле, беркайчан ару, зарлануны белмәс Шәхес булып яшәр. Аның батырлыгы турында безнең онытырга хакыбыз юк!**

# Нәрсә ул батырлык?



*«Кешене иң түбән төшерүче әйбер – ул байлык. Кеше баеп китсә, Аллаһны да, дусларын да, ата-анасы өйрәткән догаларны да оныта. Ул үзен Аллаһ, үзен хуҗа, нәрсә әйтсәм дә тыңлыйлар, дип саный. Бөеклеккә күтәрүче әйберләр кеше рухын баетырга тиеш. Һәр көнне таң ата, кояш бата, кар ява, яңгыр ява... Яңа көннәр күңелләребезгә яңа әйберләр салып куя, без аны белмибез, сизмибез, ләкин бу байлык безнең күңелләргә саекмаска ярдәм итә».*

Безнең кайсыбызның гына батыр буласы, илне шаулатырлык эшләр эшлисе килми икән?! Батыр кешеләрнең тормышлары турында укыганда, йөрәкләребез ялкынлана, җанда әллә нинди хыяллар уяна. Әйе, батырлык яшь күңелне бервакытта да битараф калдырмый, ул гел дәртләндерә, ашкындыра, матур яшәргә, матур эшләргә чакыра. Ләкин, дуслар, батырлык турында һәрберебез хыялланса да, кеше тормышындагы батырлык дигән гүзәл мизгелнең нәрсә икәнен без әле белеп бетермибез. Миңа калса, батырлыкка урын бары тик бөек көрәшләрдә генә, дигән караш күңелләрдә әле яши бугай. Дөрес, ата-бабаларыбыз, абыйапаларыбыз безгә караганда киеренкерәк чорда яшәгән. Алар революция ясаганнар, илебез өстенә албастыдай ябырылган немец фашистларын тар-мар иткәннәр. Ачлыкка, ялангачлыкка, наданлыкка каршы көрәшкәннәр. Алар тормышындагы һәр көн, һәр сәхифә батырлык булган.

Ә бүгенге көндә батырлык эшләп буламы соң? Әйдәгез, бу сорауга җавап биргәнче, батырлыкның нәрсә икәнлеге турында уйланып алыйк әле. Беренче карашка, батыр булу өчен күп нәрсә кирәкми кебек. Батыр булу өчен тәүге шарт – куркак булмау. Ә куркак булмау өчен кешегә нинди сыйфатлар кирәк?

Беренче итеп мин – халыкның күзенә туры карау, халыкны һәркем алдында ярып салу сыйфатын күрсәтеп үтәр идем. Әйтик, безнең берәр якын дустыбыз нинди дә булса начарлык эшләде, ди. Без аның белән арабыз бозылудан яки тагы да начаррагы – аның тарафыннан тукмак эләгүдән куркып, дустыбызның начарлыгын яшереп калдырдык, ди. Безнең дәшми калуыбыз куркаклык булып бәяләнергә тиеш. Чөнки батырлык ул кеше өчен көрәш, кешедәге яхшы сыйфатларны ачу өчен көрәш. Дустыбызның начарлыгына кул селтәп без ике төрле начарлык эшлибез. Берсе аның үз күңелебезгә битарафлык булып оялый, икенчесе дустыбыз йөрәгендә бәгырьсезлек булып тамыр җәя. Димәк, вакытында әйтелгән хак сүзебез дустыбызны бәладән коткарыр иде, ә кешене бәладән йолаучы кеше – батыр кеше дияргә нигезебез бар.

Үзебезнең ялгышыбызны аңлау, аны күтәрә белү өчен шактый көч сорала. Моның өчен дә куркак булмау кирәк. Кайвакыт үз кимчелегеңне, үз ялгышыңны тану башкаларның гаделсез гамәлләрен йөзенә бәреп әйтүгә караганда да авыррак була. Чөнки үз ялгышыңны таныдыңмы – аны төзәтергә кирәк. Ә үз кимчелекләреңнән арыну айһай авыр эш.

Куркак булмас өчен, вөҗданны яшьтән үк саф килеш, тапланмаган килеш сакларга кирәк. Вөҗданы саф булмаган кешеләр башкаларның күзенә туры карый алмыйлар. Алар үзләренең яман эшләре ачылудан һәрвакыт куркып яшиләр.

Куркак булмауның янә бер ягы – кешеләргә ышану. Кешеләргә ышанмаган кеше бервакытта да зур эшләр эшли алмый. Чөнки ул үзенең эшен бәяли алмаслар, кылган яхшылыгым күмелеп калыр дип курка.

Инде тагын бер мөһим сыйфатка тукталыпүтик. Ул – кешелеклелек. Дөньядагы бөтен матур эшләрнең башы нәкъ менә шуннан башлана да инде. Кешелеклелек төшенчәсе – зур мәгънәле төшенчә. Ул үзенә батырлыкны да, матурлыкны да, киң күңеллелекне дә, ярдәмчеллекне дә һәм тагын бик күп әйбәт сыйфатларны сыйдыра. Без бервакытта да әйбәт булудан, кешелекле булудан, нечкә күңелле булудан курыкмасак иде.

Тормыш безне һәркөн сыный. Алдыбызга куйган күп кенә сорауларына җавапны кайвакыт без үзебез дә белмибез. Намусыбызга тугры булсак, без ул сынауларны җиңеп чыгарбыз, халкыбыз күзенә, ата-аналарыбыз күзенә, бездән зур эшләр көткән кешеләр күзенә гел туры карый алырбыз. Шул вакытта бездән батыр кешеләр чыгар. Дөньядагы барлык батырлыклар да үз-үзеңне җиңүдән, көндәлек кыенлыклар алдында каушап калмаудан, һәр кылган эшең өчен үзеңдә җаваплылык тоюдан башлана.

*Фәнис Яруллин, 1985*

**Фәнис Яруллин иҗатын сөюче дуслар! 4 март көнне Г.Камал ис. Татар дәүләт академия театрында аны искә алу кичәсе була. Башлана 19:00 сәг.**

• Тарих сәхифәләреннән




*1923 ел*

☛**13 февраль:** Һөнәри белем бирү буенча төп идарә итү бүлеге күрсәтмәсе нигезендә, барлык югары уку йортларында фәннәрнең мәҗбүри минимумы буенча коллоквиум (имтихан) кертелгән.

☛**13 февраль:** Казан югары уку йортларының һөнәри секцияләр буенча гомумшәһәр конференциясе уздырылган. Чарада Студентлар пролетариат берләшмәсенең җиде кешесе составында Татар башкарма бюросы сайланган. 19 февральдә аның беренче утырышы уздырылган.

*1953*

☛**19 февраль:** СССР Министрлар Советы «СССРның югары уку йортларында профессор-укытучы кадрлар әзерләүне яхшырту чаралары турында» Карар кабул иткән.

*2003 ел*

☛**14 февраль:** Ректор приказы буенча КДУның Яр Чаллы филиалында «Журналистика» һәм «Икътисади кибернетика» белгечлекләре буенча дәүләт аттестация комиссиясе составы расланган.

☛**17 февраль:** Ректор приказы буенча барлык белгечлекләр һәм юнәлешләр буенча дәүләт аттестация комиссиясе составы расланган.

☛**17 февраль:** Ректор приказы буенча университетның геология факультеты деканы, доцент А.С.Борисов җитәкчелегендәге гыйльми совет расланган.

☛**19 февраль:** Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы 593 номерлы Приказ чыгарган. Аның буенча югары уку йортлары һәм белгечлекләр рейтингын билгели торган Вакытлыча методикага төзәтмәләр һәм өстәмәләр кертелгән.

• Илһам канатында

# «Axelle» ... Кемнәр ул?

**Элвина НӘҖИПОВА,**
татар филологиясе бүлеге



**Бик күпләрнең күңелен «Әйдә елмай», «Синең сурәт», «Хат», «Кар исе», «Биссмиллән» җырлары белән яулап алган «Axelle» төркеме, безнең илһамчыларыбыз белән ике атна дәвамында мастер-класслар үткәреп, якыннан аралаштылар. Соңгы ике утырышта «Илһам»да кунакта «Axelle» төркеме егетләре иде.**

Бик күпләрдә: «Ике атна буе «илһам»чылар янында нәрсә эшләгәннәр икән бу егетләр?» – дигән сорау туарга мөмкин. Хәзер мин сезгә кайбер серләрне ачарга тырышырмын.



Бу егетләрне беренче күрүчеләр игезәкләр дип атаса, якын дуслары аларның кайсысы абый, ә кайсысы энекәш икәнлекләрен бутый, кайберәүләр аларны бары тик дуслар гына дип белә. Кемнәр соң ул «Axelle» төркеменең солистлары? Аларны нәрсә бәйли һәм аерып тора?

Бу талантлы, баһадир гәүдәле бертуган ике егет – Рүзәл (*уң яктагы фотода*) һәм Рәдиф (*сул яктагы фотода)* Әхмәдиевне Аксубай ягы бүләк иткән. Рүзәл Рәдифтән бер яшькә генә өлкән булса да, үзен чын абыйларча тота. Икесе дә Казан федераль университетында белем алалар, бик актив, һәрвакыт күтәренке кәефтә, «Хәрәкәттә – бәрәкәт» девизы астында яшиләр.

Беренче утырышка кунакка Рәдиф килде. Өч сәгатькә сузылган очрашу барышында без аны бөтенләй икенче яктан ачтык. Рәдиф, абыйсыннан аермалы буларак, шаян, тапкыр телле. Битбокс белән шөгыльләнә. Бик күп туй-бәйрәмнәрне, дискотекаларны алып бара. Рәдиф, сер итеп кенә, тиздән машина йөртү таныклыгы алачагы һәм гитарада уйнарга өйрәнәчәге турында әйтте. Көннең һәр сәгате бүлеп куелган кеше кайчан ял итә соң, дигән сорау борчыды безне. Ял Рәдиф өчен җаваплы эше булмаган көн икән.

Менә Рүзәлгә килгәндә, аның белән без икенче утырышта күрештек. Рүзәл, үз вакытында, «Илһам» түгәрәгенә йөреп, каләм чарлаган кеше.

Аның 2010 елда шигырьләр китапчыгы да басылган. Рүзәлнең башка өлкәләрдә дә эшләре күп. Күптән түгел генә «Болгар радиосы»ның хәбәрләр бүлегендә эшли башлаган. «Яшьләр тукталышы» тапшыруына да репортажлар әзерли. Ирекле көрәш белән шөгыльләнә, ике төрле бию биергә өйрәнә. Тагын шунысы игътибарга лаек: мишәрстан якларыннан булсалар да, татар телендә чиста, әдәби итеп сөйләшәләр.

«Axelle» төркеме моннан ике ел элек оеша. Бу исемне таркатып карасак, ул «Ах» – Аксубай, ә «ell» Марий-Эль дигәннән барлыкка килгән. Аксубай егетләрнең үз туган яклары булуы аңлашылса, Марий-Эльдән исә егетләрнең якын дуслары бар икән. Ул аларның иҗат башлангычында терәк һәм әйдәүче кеше булып тора.

Аларның иҗаты һәркемнең күңелен биләп аладыр, минемчә. Мәсәлән, «минем вакытлыча түгел, ә вакытында буласым килгән иде», «өскә менәм, аска төшкән баскыч буйлап», «үз-үземне алдый белмим, шуңа яраларым исән», «синең кайгың яныннан хиссез үтеп барышым» һәм тагын бик күп шундый кешене уй дулкынына салырдай сүзләр. Әле ул гади җыр да түгел... Рэпта бер куплет кимендә 16 юлдан торырга тиеш. Җырның сүзләрен күбрәк Рүзәл яза икән. Үзе шаярып кына: «Сүзләрне язгач, Рәдифкә күрсәтәм. Ул шул минутта ук танышып чыга да менә монысын мин җырлыйм, дип билгеләп куя», – ди. Егетләр заказ буенча язмый икән, чөнки алай иҗатның сыйфаты кими икән.

«Сезгә тәүлекнең 24 сәгате җитәме соң», дип сорагач: «әле артып та кала», – диделәр. Менә, ичмасам, егетләр! Укытучы да икән үзләре! Безгә рэп язу серләрен дә өйрәттеләр. Әле алай гына да түгел, сезне бик зур сюрприз көтә! Ни икәнен тиздән белерсез!

**• Гашыйклар көне**

«Мәхәббәт – ул йөрәк эше. Бернинди исәп-хисап мәҗбүр итү, көчләү, ялыну-ялвару белән тудырып булмый аны. Туса ул, чәчәк бөресе ачылгандай, бары үзеннән-үзе һәм үз вакыты белән генә туа», – дип язган Әмирхан Еники. Дөрестән дә, һәр кешенең үз мәхәббәт тарихы бар. Бүген без сезне, Гашыйклар көне уңаеннан, күпләргә үрнәк гаиләләр белән таныштырабыз. Уку йортыбыз галимнәре Фираз абый һәм Чулпан апа Харисовлар, Айрат абый һәм Нурфия апа Йосыповлар гаилә серләре белән уртаклаша.

# «Икебез дә тулы хокуклы»

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

**–Очрашу тарихыгыз белән таныштырып китегез әле.**

***Ф.Ф.:*** Танышуыбыз гадәти килеп чыкты дип әйтергә кирәк. Минем уемча, фән юлына аяк атлавым шуның белән дә бәйле булгандыр. 70 еллар башы иде ул. Университетта укыганда Губкин урамындагы тулай торакта яши идек. Ул вакытта студентларда белемгә омтылыш шулкадәр зур булган ки, көндезге сәгать 2-3ләрдә үк төшеп, уку залында урын алып калалар иде. Анда укып утыру студент өчен бөтенләй яңа рух бирә иде кебек. Шулай бер көнне төшкәндә, бер кыз янында урын калган иде, аның янына барып утырдым. Икенче көнне тагы шулай булды. Соңрак бер-беребезгә урын алып калырга гадәтләндек. Бераздан тулай торакта «Язның 17 мизгеле» башланды. Беренче катта телевизор карый торган махсус бүлмә бар иде. Анда да безнең урыннар туры килде. Тагын берникадәр вакыт



үткәннән соң, мин аны «Дружба» кинотеатрына кинога чакырдым. Ул «Юк, мин егетләр белән кинога бармыйм!», – дип җавап кайтарды. Армиядән кайткан егет өчен бу бик зур «удар» иде. Яңадан чакырыр өчен, ярты ел тирәсе кыюлык тупладым. Ансында инде ризалашты...

***Ч.М.:*** 73-74 елларда Казан дәүләт педагогика институтында таныштык. Ул вакытта рус теленнән педпрактика үтә идек. Безгә күрсәтмә әсбап әзерләргә кушылган иде. Кирәк булган бар әйберебез дә бар: тушь, кисточкалар, плакатлар. Безгә матур итеп яза белә торган кеше кирәк булды. Шул максат белән без Фираз абыйларыгызның потогына мөрәҗәгать иттек. Ул матур итеп рәсем ясый, яза иде. Шуннан озак та үтми «Язның 17 мизгеле» башланды. Тулай торакта «телевизионка»да кино караганда якынрак таныштык. Шулай әкренләп очрашулар ешайды, аралашып йөри башладык. Университетны мин иртәрәк тәмамладым. Шуңа да карамастан, дуслык җепләребезне өзмәдек. 5 елга сузылган зур сынаулар үткәннән соң, ул миңа тәкъдим ясады.

**– Гаиләгездә кем баш, кем муен?**

***Ф.Ф.:*** Белмим, мин андый төшенчәне кабул итә алмыйм. Бездә андый нәрсә юк та кебек. Икебез дә тулы хокуклы дип әйтер идем.

***Ч.М.:*** Холык буенча мин командир түгел. Безнең вазыйфаларны бүлешкән дә юк. Шулай да борынгыдан килгәнчә, ир кешенең сүзе алдарак булырга тиеш дип саныйм.

**– Үзегезне романтик дип саныйсызмы, әллә күбрәк реалист дип бәялисезме?**

***Ф.Ф.:*** Мин, ир кеше буларак, реалистрактыр. Теге яки бу карарга килгәнче, мин аны шактый уйлап йөрим, баш ватам. Чулпан апагызда романтика күбрәктер дип уйлыйм. Хатын-кызда шулай булырга тиеш тә инде ул.

***Ч.М.:*** Фираз абыегыз романтик, мин реалист. Аларның Башкорстан яклары шундый бит: авызын ачсалар – җырлыйлар, яза башласалар – хикәя, шигырь язып куялар. Мин аларны романтик дип әйтер идем. Ә без, Татарстанның төньяк районнары, күбрәк реалист.

**– Сезнең өчен мәхәббәт нәрсә ул?**

***Ф.Ф.:*** Бу төшенчә күп мәгънәгә ия. Бер сүз белән генә әйткәндә, мәхәббәт ул яшәешнең, тормышның нигезе дип уйлыйм. Мәхәббәт булмаса, киләчәгебез, уңышларыбыз булыр идеме соң? Мәхәббәт булганда, яңа бурычлар куясың, аны җиңү өчен үзеңдә илаһи көч табасың.

***Ч.М.:*** Мәхәббәт ул, борынгылар әйткәндәй, бер-береңә карашып утыру гына түгел, ә бер юнәлештә карый белү. Безнең дә эш, мәшәкатьләр, тормышларыбыз охшаш.

**– Гашыйклар көнен билгеләп узасызмы?**

***Ф.Ф.:*** Безнең өчен гадәти көн инде ул. Сирәк булса да, бүләкләр бирешкән вакытларыбыз да бар.

***Ч.М.:*** Шаяртып сөйләшкәләп куябыз, әмма махсус рәвештә билгеләп үткән юк.

# «Тәүлек буе бергә»!

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче

**–Сез ничек таныштыгыз?**

***Н.М:*** Без бор чорда КДУның татар филологиясе һәм тарихы факультетында укыдык. Аннан соң, аспирантурага калып, икебез дә бер үк кафедрага беркетелдек. Укыган чорда бер-беребезгә егет белән кызга караган кебек карау юк иде. Якыннан аралашуыбыз 2003 елдан башланды, ахрысы. Дөресрәге, безнең якынаюда Дания апа Заһидуллинаның да өлеше булды, дисәм дә ярыйдыр. Айратның миңа аерым игътибар итә башлавын күреп, ул: «Нурфия, нишләп Айратка игътибар итмисең син, фән өчен генә яшәп булмый бит. Ул бит менә дигән гаилә кешесе булачак», - дигән иде. Аннан соң Аксубай районына Хәсән Туфан музеена сәяхәткә кайттык, шуннан якынаеп киттек. Бер-беребезне яхшы белгәннән соң гына, 2006 елда гаилә корып җибәрдек.

**– Гадәттә, кеше тормыш иптәшен я әтисенә, я әнисенә охшата диләр?**

***Н.М.:*** Әтием бик яхшы кеше иде. Булачак иремнең дә шундый булуын теләгән идем. Айрат та әтиемә охшаган булып чыкты. Ул – гаиләдә искиткеч кеше. Кызыбызны искиткеч ярата, аның алдында зур җаваплылык хисләре белән яши. Язмышыма аның белән очраштырганы өчен рәхмәтле.

***А.Ф.:*** Мин Нурфияне әниемә бик охшатам. Алар икесе дә бик максатчан кешеләр. Гаиләдәге җылылыкны, тынычлыкны саклау өчен әнием дә күп көч куя иде, Нурфия дә нәкъ шундый кеше.

**– Сезнең гаиләдә кем – баш, кем –муен?**



***А.Ф.:*** Мин, ир-ат буларак, гаиләнең матди ягын, тормыш кирәк-ярагын кайгыртам, ир-атлар эшли торган эшләрне башкарам. Гаиләнең эчке халәте өчен хатын-кыз җаваплы. Мин – баш, Нурфия апагыз – муен. Болай әйткәндә дә, муен башны ничек бора бит әле. Акыллы хатын-кыз, гадәттә, үзе читтә калган хәлдә, ир-ат белән идарә итә, «башны бора» ала. Нурфия апагызда да мондый сыйфат бар. Кайбер мәсьәләләрне хәл иткәндә, үз мөнәсәбәтен төгәл генә ачып салмыйча, миңа хәл итү мөмкинлеген калдыра, ләкин шул ук вакытта сиздермичә генә үз фикерен үткәреп җибәрә белә.

**– Сез эштә дә, өйдә дә бергә. Бу мөнәсәбәтләрдә чагылыш табамы?**

***Н.М.:*** Без тәүлек буе бергә, ләкин бер-беребездән ялыкмыйбыз. Беребез эштә булмаса, нindидер бушлык бар сыман. Фән кешесенең фән кешесе белән бергә булуы кирәктер дип уйлыйм мин. Без бит гел китап укучы, эзләнүче, мәкалә яки ниндидер хезмәт язучы кеше. Башка өлкә кешесе безне аңламас иде. Әйтик, мин фәнни мәкаләләр эшләп утырам икән, Айрат бала карый. Шулай булмаса, кызыбызга 6 ай вакытта Дания Фатыйховна белән дәреслек яза алмас идем. Аннан соң безнең гаилә һәм эш чикләре билгеләнмәгән. Кемнеңдер эше бетә, гаиләсе башлана. Ә безнең алар бербөтен.

**– Сез Гашыйклар көне бәйрәменә ничек карыйсыз? Гаиләгездә үткәрәсезме?**

***Н.М.:*** Безнең гаиләдә никах, туй көнебез, Айрат, Камилә һәм минем туган көннәр генә зур бәйрәм.

***А.Ф.:*** Әгәр бер-береңне аңлап, яратып яшәсәң, көн дә бәйрәм! Шуңа күрә һәр көннең кадерен белеп, яратып, гаилә бәхетен тоеп яшим. Махсус бәйрәм ясамасак та, бу уңайдан Нурфия апагызга чәчәк бәйләме бүләк итәчәкмен.

**– Яшь парларга, гаилә корырга теләүчеләргә нинди теләкләр әйтер идегез?**

***Н.М.:*** Без, әлбәттә, әле яшь, гаилә өлкәсендә дә зур тәҗрибәсе булган кешеләр түгел. Шулай да гаилә корып җибәрү – әле бик кечкенә эштер ул. Аны бөтенлекле итеп саклау, тормыш авырлыкларын бергәләп җиңү бары тик үзләреннән генә тора. Бүгенге шартларда гаиләне тулы итеп, бәхетле, бөтенлекле итеп яшәтү ирдән дә, хатыннан да зур көч таләп итә.

***А.Ф:*** Үзләре ошаткан, яраткан, үзләренә тиң булган кешеләр белән гаилә корсыннар иде. Яшь чактагы җылы хисләрне гомер буе саклап, араларына башка кешеләрне, салкын җилләрне кертмәсеннәр иде.

**• Дөнья үзебезнеке**

# «Әйдә, өйләнешәбез»!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Соңгы елларда бу бәйрәмне үткәрү яшьләр арасында аеруча популярлык казанды. Руслар аны «Изге Вәли көне» дип атый, ә без татарчалаштырып, «Гашыйклар көне» дибез. Чит илдә бу уңайдан төрле гореф-гадәтләр, ышанулар да яши икән...

♥ Италиядә әлеге бәйрәмне «татлы» көн дип йөртәләр. Бу көнне Италия гашыйклары бер-берсенә йөрәк формасында ясалган кәнфитләр һәм башка баллы ашамлыклар бүләк итәләр.

♥ Америкада да гашыйкларны тәм-том белән сыйлау гадәте бар. XIX гасырда карамель продукциясе барлыкка килә. Аклы-кызыллы төстәге суыра торган кәнфитләргә Изге Вәли көнне әйтергә теләгән сүзләр һәм теләкләр язылган. 50 елларда йөрәк формасындагы шоколад кәнфитләр популярлаша башлый. Бу көнне алар якын һәм кадерле булган башка кешеләрне дә тәбриклиләр.

♥ Англиядә бу көнне котлау сүзләре кешеләр белән беррәттән, яраткан йорт хайваннарына да барып ирешә. Изге Вәли көнендә иң популяр бүләкләр булып, йөрәк формасындагы тәм-томнар һәм йомшак уенчыклар санала. Британ халкы бигрәк тә Teddy аюларына мөкиббән икән.

♥ Иң романтик милләт булып танылган французлылар валентинкаларга аерым басым ясый. Тагын бу көнне шоколад кәнфитләр, йөрәк формасында киселгән колбаса, «Мин сине яратам» дип әйтә торган сувенирлар бүләк итү каралган. Тәкъдим ясау өчен, иң кулай көн булып исәпләнә. Кайсы гына хатын-кыз елның иң романтик көнендә кулын сорагач, баш тартыр икән?

♥ Голландиядә 14 февральдә хатын-кыз ир кешегә өйләнешергә тәкъдим итә ала. Әгәр ул баш тартса, «компенсация» рәвешендә, асыл затка ефәк күлмәк алып бирергә тиеш була. Бу традицияне бәлки бездә дә кертеп җибәрергә кирәктер? Кызлар, ни диярсез?

♥ Япониядә Изге Вәли көне Ватанны саклаучылар көне альтернативасына әйләнгән. Бу көнне көчле затларны бүләк һәм тәбрикләүләргә күмәләр.

♥ Уэльста «мәхәббәт кашыклары»н бүләк итешәләр. Кулдан эшләнгән сувенирларга йөрәк, йозак һәм ачкыч бизәкләре төшерелә.

♥ Германиядә 14 февраль психик авырулар көне булып исәпләнә. Бу бәйрәм уңаеннан, психик хастаханәләрдә кызыл төстәге ленталар элеп чыгалар, соборларда махсус гыйбадәт кылулар оештыралар

Кайсыбер илләрдә бу бәйрәм, гомуммән, тыелган. Мәсәлән, Иран һәм Согуд Гарәбстанында канунга буйсынмаучыларга штрафлар да билгеләнгән. Әлеге дәүләт вәкилләре бу бәйрәмне куркыныч дип саныйлар. Янәсе, ул Көнчыгыш илләренең гөнаһлы традицияләрен пропагандалап, кешеләрнең аңнарын томалый икән.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.